**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Үчәлле авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Үчәлле авылы №76 "21 "декабрь 2022 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге Советының 2014 елның 24 гыйнварындагы 87 номерлы авыл җирлеге Советының карары белән расланган, Азнакай муниципаль районы «Үчәлле авыл җирлеге» җирдән файдалану һәм муниципаль берәмлек төзелеше кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында (22.11.2016 ел №46, 22.11.2016 ел №47, 02.09.2017 ел №66, 03.07.2018ел №104, 15.03.2019 ел №136, 19.02.2020 ел №169, 05.08.2021ел №36, 17.06.2022 ел №63 карарлар редакциясендә)

Муниципаль норматив хокукый актларны Россия Федерациясенең гамәлдәге шәһәр төзелеше кодексына туры китерү һәм 2022 елның 14 июлендәге 350-ФЗ номерлы «Россия Федерациясенең шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында " Федераль законны үтәү максатыннан

Үчәлле авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге Советының от 22.11.2016 №46, от 22.11.2016 №47, от 02.09.2017 №66, от 03.07.2018 №104, от 15.03.2019 №136, от 19.02.2020 №169, от 05.08.2021 №36, от 17.06.2022№63) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 25 статьяның 2 өлешендәге 4 пунктын «, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә торган критерийлар» сүзләре белән тулыландырырга.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда түбәндәге веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга: http://aznakayevo.tatarstan.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге Советының торак-коммуналь хуҗалык, төзекләндерү, экология һәм җир мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис Г.М.Төхвәтуллина